МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.06.2020 г.Казань № 400

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 13 июлендә 6754 номеры белән теркәлде

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы «Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» боерыгы белән расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы «Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» боерыгы белән расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 8 июнендәге 400 номерлы боерыгы белән расланган

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы «Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» боерыгы белән расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы «Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» боерыгы белән (Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 ел № 317, 31.10.2016 ел № 612, 08.06.2017 ел № 349, 01.06.2018 ел № 426, 18.09.2018 ел № 860, 23.04.2019 ел № 297, 14.11.2019 ел № 1021, 10.02.2020 ел № 84 боерыклары керткән үзгәрешләр) белән расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.5.2 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба - министрлык) http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында; Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.5.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.7 пунктта:

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру

турында» Федераль законы (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Торак кодексындагы 159 маддәнең 1 пункты; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 29 декабрендәге 665 номерлы карары белән расланган Торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә халыкка өстәмә социаль ярдәм күрсәтү турында нигезләмәнең 1.2 п. (алга таба - 665 номерлы Нигезләмә)»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 14 декабрендәге 761 номерлы карары белән расланган Торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирү кагыйдәләренең 7 п. (алга таба - 761 номерлы Кагыйдә)»;

2.5 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаиләнең барлык әгъзалары һәм туганлык дәрәҗәсе, социаль түләүләрне алу өчен почта адресы яисә кредит оешмасында федераль законнар нигезендә ачылган счет реквизитлары күрсәтелгән, түбәндәге документлар теркәлгән, шулай ук түбәндәге белешмәләр кертелгән гариза (гаризаның формасы әлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән):

гариза бирүче хосусый торак фондында наем шартнамәсе буенча торак урын яллаучы булса, гариза бирүче хосусый торак фондына, торак, торак-төзелеш кооперативы яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзасы булган очракта, даими яшәү урыны буенча теркәлгән торак урынына ия булуның һәм аннан файдалануның хокукый нигезләрен раслый торган документлар турында белешмәләр. Хәрби часть адресы буенча яшәү урынына теркәлгән контракт буенча хәрби хезмәт узучы, торак урыннарда хезмәт урыннары булмау сәбәпле наем (кече наем) шартнамәсе буенча яшәсә, гаризага кушымта итеп хосусый торак фондында наем (кече наем) шартнамәсенең күчермәсен һәм хәрби частьтән хезмәт урынында тору мөмкинлеген биреп булмау турында белешмәне тапшыра;

гариза бирүче белән бергә даими яшәү урыны буенча теркәлгән, ләкин гаризада гаилә әгъзалары буларак күрсәтелмәгән гражданнар тарафыннан торак урынын карап тоту, ремонтлау һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен раслый торган документлар;

гариза бирүченең - чит ил гражданының һәм аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе тарафыннан субсидияләр бирү турында халыкара шартнамә төзелгән дәүләтнең гражданы булуын раслый торган документларның күчермәләре;

субсидия бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре турында белешмәләр.

Гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре булмаган очракта, гариза бирүче өстәмә рәвештә гражданнарның керемнәре булмавын раслый торган документларның күчермәләрен бирә, аларга түбәндәгеләр керә:

а) урта һөнәри белем бирүнең һәм көндезге уку формасы буенча төп белем бирү программалары буенча белем алучы мәгариф оешмаларында укучы 23 яшькә кадәрге гражданнар өчен - стипендия булмау турында белешмә;

б) эшләмәүче гражданнар өчен - соңгы язмасы эштән азат итү турында булган, билгеләнгән тәртиптә таныкланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;

в) гражданнарның эшкә урнашу мөмкинлеге булмаган яисә чикләнгән затлар категорияләренә каравын раслый торган документ, аларга түбәндәгеләр керә:

алдан тикшерү һәм суд тикшерүе чорына сак астында торучы затлар;

озак стационар дәвалануда булган затлар (әлеге дәвалану чорында);

билгеләнгән тәртиптә хәбәрсез югалган дип танылганга яисә вафат булган дип игълан ителгәнгә кадәр эзләүдә булган затлар;

3 яшькә җиткәнче баланы карап торучы, 1,5 яшь тулганчы бала карау буенча отпуск чорына айлык пособие алмаучы һәм хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торып, 3 яшькә җиткәнче бала карау ялында булган гражданнарга айлык компенсация түләүләре алмаган аналар.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) я гариза бирүче билгеләгән вәкаләтле затлар өстәмә рәвештә гариза бирүче мәнфәгатьләрен тәкъдим итүгә үз вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен тапшыралар.

Гариза бирүче белән бергә даими яшәү урыны буенча яшәүче затлар арасында бер гаиләгә карау мәсьәләсе буенча каршылыклар булса, гариза бирүче даими яшәү урыны буенча аның белән бергә яшәүче затларны аның гаилә әгъзалары дип тану турында суд актының күчермәсен тапшырырга хокуклы.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләре белән тапшырыла һәм Үзәк бүлегенең белгече тарафыннан таныклана.

Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә паспорт яки шәхесне раслаучы башка документ күрсәтә.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа кушып бирелә торган документларның күчермәләре (шәхесне раслаучы документның күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә расланырга тиеш.

Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда шәхсән яисә почта аша искәртмәле хат белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гариза һәм документларның күчермәләре электрон документлар рәвешендә Үзәк бүлегенә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, «Интернет» челтәрен аша да җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр гариза бирүче тарафыннан түбәндәге урыннарда алынырга мөмкин:

эш бирүченең соңгы эш урыны буенча (әлеге эш бирүчедә эшләгән чорда) тиешле рәвештә расланган кәгазьдә яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган электрон документ формасында (эш бирүчедә булганда);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә тиешенчә расланган кәгазьдә;

Россия Федерациясе Пенсия фондында тиешле рәвештә расланган кәгазьдә яисә көчәйтелгән квалификацияләнгән электрон имза куелган электрон документ формасында;

дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталын көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә куллану»;

«Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Методик тәкъдимнәр» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 14 декабрендәге 761 номерлы карары, 2016 елның 30 декабрендәге Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 1037/пр номерлы һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 857 номерлы уртак боерыгы белән расланган Торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирү кагыйдәләрен куллану буенча методик тәкъдимнәр (алга таба - Методик тәкъдимнәр)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәге белешмәләр булган документлар алына:

дәүләт тарафыннан торак урынга (фатирга, торак йортка, фатирның яисә торак йортның бер өлешенә) милек хокукының теркәлүе турында (Теркәү, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсендә);

дәүләт тарафыннан тууның теркәлүве турында (вәкаләтле органнарда);

дәүләт тарафыннан никахлашуның теркәлүве турында (вәкаләтле органнарда);

дәүләт тарафыннан аерылышуның теркәлүве турында (вәкаләтле органнарда);

бала өстеннән опека билгеләү турында (җирле үзидарә органнарында);

тәрбиягә алучы гаиләгә баланы тапшыру турында (җирле үзидарә органнарында);

дәүләт яисә муниципаль торак фондындагы торак урынын файдалану хокукының барлыгы турында (вәкаләтле органнарда);

гариза бирүче белән бергә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында (вәкаләтле органнарда);

эшсезлек буенча пособие күләме, эшсез гражданнарга матди ярдәмнең һәм башка түләүләрнең күләме, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри уку һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм күләме, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлыча эшләрдә катнашу чорында түләүләр күләме, шулай ук 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга аларның вакытлыча эшләргә катнашу чорында түләүләр күләме турында (халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләрендә (алга таба - халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре));

торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр турында, торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурыч булу (булмау) турында (идарәче компанияләрдә);

торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары буларак алына торган түләүләр күләме турында (социаль яклау органнарында);

Россия Федерациясе Пенсия фонды башкара торган пенсионерларның пенсияләре, компенсация түләүләре һәм өстәмә айлык матди тәэмин ителеше турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

Россия Эчке эшләр министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында (Россия Эчке эшләр министрлыгында);

Россия Оборона министрлыгы тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында (Россия Оборона министрлыгында);

медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча, һөнәри эшкә яраклылык югалган булса, медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча, иминиятләштерелгән затның үлеме иминият очрагы килеп туган очракта, җитештерүдәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча айлык иминият түләүләре турында (Россия Федерациясе Социаль иминият фондында);

вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособие турында (Россия Федерациясе Социаль иминият фондында);

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының социаль яклау органнары яисә территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала табу буенча пособие күләме турында (Россия Федерациясе Социаль иминият фондының социаль яклау органнарында яисә территориаль органнарында);

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының социаль яклау органнары яисә территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелекнең иртә вакытларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга бер мәртәбә бирелә торган пособие күләме турында (Россия Федерациясе Социаль иминият фондының социаль яклау органнарында яисә территориаль органнарында);

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының социаль яклау органнары яисә территориаль органнары тарафыннан түләнә торган баланы карау буенча ай саен түләнә торган пособие күләме турында (Россия Федерациясе Социаль иминият фондының социаль яклау органнарында яисә территориаль органнарында);

шәхси исәп-хисап счетының иминият саны турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

субсидия бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре турында (вәкаләтле органнарда);

гариза бирүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының ташламаларга, социаль ярдәм чараларына, торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча компенсацияләргә хокуклары турында;

гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе гражданлыгын таныклый торган документлар турында (Россия Эчке эшләр министрлыгында).

Гариза бирүче югарыда күрсәтелгән белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы.

Күрсәтелгән документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон формада алынырга һәм әлеге Регламентта, 2.5 пунктта каралган тәртиптә билгеләнгәнчә тапшырылырга мөмкин.

Гариза бирүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмау гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуы өчен нигез булып тормый.

Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәткәндә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне көйли торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә үтәү каралмаган гамәлләрне тормышка ашыру өчен документлар һәм мәгълүмат бирү;

210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен түләү кертүне раслаучы документларны һәм мәгълүматларны;

№ 210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсендәге 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирүне»;

2.8 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында:

2.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1 п.(алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)»;

2.15 пунктта «880 номерлы тәртип» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.3.2.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацларны өстәргә:

«субсидия бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре турында (вәкаләтле органнарда);

гариза бирүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының ташламаларга, социаль ярдәм чараларына, торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча компенсацияләргә хокуклары турында;

Россия Федерациясе гражданлыгын таныклый торган документлар турында (Россия Эчке эшләр министрлыгында).»;

3.4.2.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацларны өстәргә:

«субсидия бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре турында (вәкаләтле органнарда);

гариза бирүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының ташламаларга, социаль ярдәм чараларына, торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча компенсацияләргә хокуклары турында;

Россия Федерациясе гражданлыгын таныклый торган документлар турында (Россия Эчке эшләр министрлыгында).»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче кушымта<br>Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә<br>түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча<br>дәүләт хезмәте күрсәтүнең<br>административ регламентына

форма

РЦМП (КВ) бүлегенә № _____

______________________________<br>муниципаль районында (шәһәрендә)

Торакка һәм коммуналь хезмәтләр<br>күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү турында<br>гариза

Мин,

________________________________________________________________________,<br>(гариза бирүченең тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)<br>түбәндәге адрес буенча яшәүче:

________________________________________________________________________,<br>(гариза бирүченең индексы күрсәтелгән почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)<br>түбәндәге документ нигезендә гамәл кылучы:

________________________________________________________________________

(ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклый торган затның вәкаләтләрен раслый торган документның реквизитлары)

1. Торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия бирүегезне сорыйм.

2. Гариза бирүче белән бергә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гаилә әгъзалары турында белешмәләр:

| № п/п | Фамилия, исеме, атасының исеме (булганда) | СНИЛС | Туганлык дәрәҗәсе | Шәхесне таныклый торган документ реквизитлары | Ташламалар (социаль ярдәм чаралары, компенсацияләр) барлыгы | Керемнәр турында мәгълүмат[2] (ай/сумма (сум)) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1[1] | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| 2 | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

[1] Беренче юл белән гариза бирүче турында белешмәләр күрсәтелә.

[2] 6 календар ай эчендә алынган керем күләме күрсәтелә (айлап). Күрсәтелгән 6 айлык чорны санау субсидия бирү турында гариза бирелгән айга кадәр 6 ай кала башлана.

3. Гариза бирүче белән даими яшәү урыны буенча теркәлмәгән һәм гариза бирүчегә яисә гаризаның 2 пунктында күрсәтелгән аның гаилә әгъзаларына карата ир (хатын), балигъ булмаган балаларының ата-анасы яисә уллыкка алучылары, шул исәптән уллыкка алынган балалар турында белешмәләр.

| № п/п | Фамилия, исеме, атасының исеме (булганда) | СНИЛС | Гаризаның 2 пунктында күрсәтелгән гражданның туганлык дәрәҗәсе һәм фамилиясе, исеме, атасының исеме | Шәхесне раслаучы документ (реквизитлар) | Керемнәр турында мәгълүмат[1] (ай/сумма (сум)) |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| 2 | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

[1] 6 календар ай эчендә алынган керем күләме күрсәтелә (айлап). Күрсәтелгән 6 айлык чорны санау субсидия бирү турында гариза бирелгән айга кадәр 6 ай кала башлана.

4. Гариза бирүче даими яшәү урыны буенча теркәлгән торак урынына ия булуның һәм аннан файдалануның хокукый нигезләрен раслый торган документлар турында белешмәләр (гариза бирүче хосусый торак фондында наем шартнамәсе буенча торак урынны яллаучы, торак, торак-төзелеш кооперативы әгъзасы яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы булган очракта күрсәтелә).

_______________________________________________________________________

5. Билгеләнгән түләүләрне түбәндәгечә тапшыруыгызны сорыйм:
түбәндәге счетка күчерү юлы белән:

_______________________________________________________________________

(гариза бирүче я аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачылган счетның реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлеге аша ___________________________________________________

(гариза бирүченең я аның законлы вәкиленең почта бүлеге реквизитлары күрсәтелә)

6. Тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, алар булган документларның дөреслеге өчен җаваплылык турындагы һәм торак урыны белән коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия билгелгәндә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында үз вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым
Гариза бирүче: «____» ______________ 20__ ел.

Гариза бирүченең яисә аның мәнфәгатьләрен билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышанычнамә нигезендә яклаучы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (имзасы).

7. Мәгълүмат алуга риза, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында

_____________________________________________________________________________

(почта адресы, смс-хәбәр, электрон почта буенча, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша)

___________________________/________________________/ "__" ________ 20__ ел.

гариза бирүченең яисә аның мәнфәгатьләрен билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышанычнамә нигезендә яклаучы зат имзасы

Гариза һәм _________ данә документ кабул ителде.
___________________________/________________________/ "__" ________ 20__ ел.
(вазыйфаи зат имзасы) (фамилия) (дата)
Эш формалаштырылды
___________________________/________________________/ "__" ________ 20__ ел.
(вазыйфаи зат имзасы) (фамилия) (дата)
Эш тикшерелде
___________________________/________________________/ "__" ________ 20__ ел.
(җитәкче имзасы) (фамилия) (дата)
Аеру сызыгы

Расписка-искәртмә

Гариза бирүченең теркәлү № __________
Документ саны ____ санда, ____ биттә
Документларны кабул иттем __________ _____________ ______________ __________ 20__ ел.
(вазыйфа) (имза) (имза ачыкламасы) (дата)».